**“Татар кызы – 2019” республика бәйгесе турында мәгълүмат**

Татарстан Республикасы мәгариф министрлыгы планы буенча 2019 нчы елның 29 нчы ноябрендә Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте – Казан арты милли кадрлар әзерләү үзәгендә урта һөнәри белем бирүче уку йортлары студентлары арасында республикакүләм “Татар кызы – 2019” бәйгесе уздырылды. Бәйгенең 1 нче (сайлап алу) турында 34 уку йортыннан килгән студент кыз көч сынашты. “Татар кызы, син замана гүзәле!” темасына үткәрелгән визит карточкасы һәм “Без тарихта эзлебез” темасына үткәрелгән интеллектуаль конкурста югары баллар җыйган 11 конкурсант 2 турга үтте.

2 нче турда “Белем белен ашата” бәйгесендә кызлар татар халык камыр ашларын пешерү серләре белән уртаклаштылар, “Театр көлдерәдер, уйнатадыр...” бәйгесендә татар драматургларының әсәрләреннән алынган өзекләр аша актерлык сәләтләрен, “Матурлык дөньяны коткарыр” бәйгесендә кул эшенә осталыкларын, “Сәхнәдә мин яшим!” экспромт бәйгедә төрле ситуацияләрдән чыга белү осталыкларын күрсәттеләр. Мәртәбәле жюри конкурсантларның чыгышларын түбәндәгечә бәяләде:

**1 урын - Рахманова Зәхинә,** ДАҺБУ “М. Җәлил ис. Минзәлә педагогия көллияте”;

**2 урын - Юсупова Лилия**, ДАҺБУ “Казан энергетика көллияте”;

**3 урын - Галявина Ләйсирә** ДАҺБУ “Казан педагогия көллияте”;

**“Тапкыр кыз”** номинациясе – **Заһидуллина Зилә Фарил кызы**, ДАҺБУ «Буа ветеринария техникумы»;

**“Зирәк кыз”** номинациясе – **Петрова Лилиана Андрей кызы**, ДАҺБУ «Түбән Кама педагогика көллияте»;

**“Ягымлы кыз”** номинациясе – **Фәрдиева Динара Ленар кызы**, ДАҺБУ «Яр Чаллы педагогия көллияте»;

**“Уңган кыз”** номинациясе – **Нәҗмиева Алинә Рәшит кызы**, ДАҺБУ «Яшел Үзән механика көллияте»;

**“Сөйкемле кыз”** номинациясе – **Ризванова Регина Артур кызы**, ДАҺБУ «Бөгелмә машина төзелеше техникумы»;

**“Тамашачы мәхәббәтен яулаган кыз”** номинациясе  – **Хәмидуллина Әдилә Шәфыйкъ кызы**, ДАҺБУ “Г.Тукай исемендәге Әтнә авыл хуҗалыгы техникумы”;

**“Иң җитез кыз”** номинациясе  – **Нуруллина Диләрә Рифат кызы**, ДАҺБУ «Казан радиомеханика көллияте».

ДАҺБУ “Г. Тукай им. Арча педагогия көллияте”ннән **Бәйрәмова Динә**,  конкурстан тыш катнашып, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының махсус бүләгенә лаек булды.